**Шәһәр күләмендә Татар халкы һәм Татарстан тарихы фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың шәһәр этабы биремнәре**
**2024-2025 нче уку елы**
**10-11 сыйныф**

**Эшне башкару вакыты – 90 минут**
**Гомуми балл – 84**

***1 бүлек. Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз.***
***(Һәр дөрес җавап өчен 1 б. Иң югары – 5 б.)***

**1. Төрки каганлыкның барлыкка килүен әлеге нәсел белән бәйлиләр. Риваять буенча, ыруның башы кырып бетерелгән кабиләдән калган малайны асрап үстергән ана бүредән килә. Алардан соңыннан Көнчыгыш Төркестанның Турфан оазисыннан булган кызларга өйләнгән ун ир бала туган. Кайсы нәсел турында сүз бара? (1 б.)**
А) Сөннәр
Б) Ашыннар
В) Аварлар
Г) Гуннар
**Җавап:** ___________________________

**2. Россия мөселманнары Диния нәзарәтенең беренче мөфтие кем булган?(1 б.)**
А. Мөхәммәтҗан Хөсәенов
Б. Сәгыйт Хәлфин
В. Шиһабетдин Мәрҗани
Г. Каюм Насыйри
**Җавап:** ___________________________

**3. «Өстә - күк Тәңре, аста - көрән җир кылынганда ике арада кеше углы барлыкка килде» сүзләре белән башланган язма кайсы хакимгә багышланган? (1 б.)**
А. Сафагәрәй
Б. Билге каган
В. Күлтәгин
Г. Чыңгыз хан
**Җавап:** ___________________________

**4. Түбәндәге шәхесләрнең кайсысы Казан университетында укыткан?**
А. Шиһабетдин Мәрҗани
Б. Каюм Насыйри
В. Ибраһим Хәлфин
Г. Риза Фәхретдинов
**Җавап:** ___________________________

**5. Танылган мәгърифәтче Фатих Кәрими чыгарган газета:**
А. “Нур”
Б. “Ватаным Татарстан”
В. “Вакыт”
Г. “Мәгариф”
**Җавап:** ___________________________

*2 бүлек. Туры китерүгә, эзлеклелекне, артык элементны һ.б. билгеләүгә нигезләнгән биремнәр*

**6. Төрки халыклар тарафыннан билгеләп үтелә торган бәйрәмнәрне хронологик тәртиптә (1 гыйнвардан алып) урнаштырыгыз. (Дөрес тәртиптә урнаштырылган җавап өчен 5 б.).**

| | |
|---|---|
| А) Җыен | |
| Б) Нардуган | |
| В) Нәүрүз | |
| Г) Сабан туе | |
| Д) Каз Өмәсе | |

**7. Татарстан Республикасының фән һәм сәнгать әһелләрен аларның эшчәнлек төрләре белән туры китерегез. (Һәр дөрес җавапка 1 б., иң югары – 10 б.)**

| Фән һәм сәнгать әһелләре | Эш төрләре |
|---|---|
| 1. Гыйлем Камай | А. Язучы |
| 2. Гомәр Бәширов | Б. Композитор |
| 3. Рөстәм Яхин | В. Шагыйрь |
| 4. Бакый Урманче | Г. Әдәбият галиме |
| 5. Сибгат Хәким | Д. Химик галим |
| 6. Таҗи Гыйззәт | Е. Сынчы |
| 7. Мөнирә Булатова | Ж. Драматург |
| 8. Мөхтәр Мутин | З. Тарихчы |
| 9. Ибраһим Нуруллин | И. Җырчы |
| 10. Миркасыйм Госманов | К. Артист |

**Җавап:**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |

**8. Исемлектәге шәхеснең кайсысы әлеге рәткә туры килми һәм ни өчен? (тулы җавап өчен 2 б.)**

1) Галимҗан Ибраһимов
2) Заһидулла Яруллин
3) Мөсәгыйть Хәбибуллин
4) Разил Вәлиев

**Җавап: ______________________________**

**9. Туры китерү ысулы белән сорауларга җавап бирегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары – 12 б.)**

| Сорау | Җавап |
|---|---|
| 1. Бу патшабикә Казан яулап алынганнан соң көчләп Шаһгалигә кияүгә бирелә. Аның исемен атагыз. | А.Мөхлисә Бубый |
| 2. 1718 елгы указ нигезендә кораб төзү өчен урман кисү эшләрен йомышлы морзалар, татарлар, мордва һәм чуашлар башкарган. 1859 елда алар дәүләт крестьяннарының гомуми катлавына кертелә. Атамасы? | Б. 1770 ел. Мәрҗани мәчете |
| 3. 1552 елда һәлак булган шагыйрь, дәүләт эшлеклесе, сәид исеменә Казанда бүгенге көннәрдә салынган мәчетнең ачылу елын һәм исемен атагыз. | В. “Йомышлы кешеләр” |
| 4. XV-XVII гасырларда Рус дәүләтенә хәрби хезмәт итүчеләр. | Г. 2005 ел. Кол Шәриф мәчете |

| | |
|---|---|
| 5. Мөселман дөньясында беренче казыясы (хатын-кыз казыйны) атагыз. | Д. Сөембикә |
| 6. 1552 елдан соң Казанда беренче таш мәчет кайсы елны төзелә һәм аның хәзерге исеме ничек? | Е. Лашманнар |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**10. Түбәндәге җөмләләрнең кайсылары дөрес, ә кайсылары чынбарлыкка туры килмәгәнлеген ачыклап, таблицаны тутырыгыз. (Һәр дөрес җавап өчен 1 б. Барлыгы 10 б.).**

1. 1804 елда Казан универитеты ачыла.
2. 1906 елда Оренбургта "Хөсәения" мәдрәсәсе ачыла.
3. I Бөтенроссия мөселман корылтае 1920 елда уза.
4. Беренче татар балетының авторы – Нәҗип Җиһанов.
5. Ш.Мәрҗани КТУШта укыта.
6. XIX гасырда татар укытучылар мәктәпләре Симферополь, Уфа, Казан, Оренбург шәһәрләрендә булган.
7. "Тәрҗеман" газетасының редакторы И.Гаспралы була.
8. 2000 елда Казан шәһәренең 1000 еллыгы бәйрәм ителә.
9. 2005 елда Казан метросының беренче линиясе ачыла.
10. Беренче милли "Сания" операсын өч композитор иҗат итә.

| **Дөрес** | **Ялгыш** |
|---|---|
| | |

**11. Түбәндәге шәхесләр тарихта нәрсә белән билгеле? Аларның эшчәнлекләрен кыскача тасвирлагыз. (Һәрбер дөрес җавап өчен 3 б., иң югары – 12 б.)**

1. Садри Максуди (1878-1957)
2. Фәрит Мөхәммәтшин (1947)
3. Гыйлем Камай (1901-1970)
4. Гаяз Исхакый (1878-1954)

**Җавап:**

1. ____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

2. ____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

3. ____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

4. ____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

*3 бүлек. Рәсемнәр белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр*

**12. XIX гасыр Казан университеты галимнәренең фоторәсемнәрен аларның фәнни казанышлары белән туры китерегез. Җавапны таблицага языгыз. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б. Иң югары 16 б.)**






| А | Б | В | Г |
|---|---|---|---|

1. Казан университеты ректоры (1827-1846), профессоры. Евклид булмаган геометрияне ачучы.
2. Казан университеты ректоры (1846-1855), профессоры. Казан астрономия мәктәбенә нигез салучы. 1820 елда Антарктикага ясалган сәяхәттә катнашып, әлеге материкны ачучыларның берсе.
3. Казан университеты профессоры. Казан химия мәктәбенә нигез салучы. 1842 елда анилин химик кушылмасын ачучы.
4. Казан университетында фарсы, гарәп, төрек, татар телләре укытучысы, профессор. Ул төзегән «Төрек-татар теленең гомуми грамматикасы» Петербург университетының Демидов премиясенә лаек була.

**Җавап:**

| **Галим** | **Фоторәсем** | **Тасвирлама (№)** |
|---|---|---|
| Николай Николаевич Зинин | | |
| Александр Касимович Казем-Бек | | |
| Николай Иванович Лобачевский | | |
| Иван Михайлович Симонов | | |

*4 бүлек. Чыганак текстлары белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр*

**13. Чыганактан өзекне укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез. (Иң югары 12 б.)**

*[...] Пролетариат диктатурасы шартларында сәнгать дөньясында операга урын бармы? [...] Совет операсы үзенең башлангыч адымнарын гына атлый. Рус сәнгать дөньясында да әле опера өлкәсендә совет репертуары туганы юк; опера театрлары һаман шул иске, черек идеологияле буржуа репертуарын дәвам итәләр.*

*Менә шундый шартлар эчендә чын мәгънәсе белән пролетариат тормышын һәм пролетариат идеологиясен гәүдәләндергән беренче опера татар арасында дөньяга килде. Чынлап та, татар җәмәгатьчелегенең моның белән мактанырга хакы бар. Бер дә кичектермичә, "Эшче" операсын бөтен союз халыклары арасында күрсәтергә, популярлаштырырга кирәк.*

*Әгәр без "Эшче" операсын шул ук коллектив тарафыннан моннан биш ел элек язылган "**...**" операсы белән чагыштырсак, кирәк техника, кирәк идеология ягыннан булсын, искиткеч алга китү күрәбез. Үзе 1925 елда гына язылганына карамастан, "**...**" операсы баштанаяк либераль буржуа сәнгате әсәре булып чыккан иде. [...]*

*“Эшче”дә бөтенләй башка хәл күрәбез. Сюжет ягыннан анда татар крестьянының пролетарлашуы һәм революцион көрәш моментлары алына. Идеология ягыннан ул сыйнфый көрәш идеологиясен алга сөрә. Музыка ягыннан ул шактый эшләнгәнербөтен булып, интернациональ музыкага таба зур адым ясый. Интернациональ музыка өлешендә ифрат уңышлы рәвештә бирелгән завод-фабрик тавышларының грандиоз ритмикасы һәм “Марсельеза”, “Интернационал” шикелле революцион мотивлар аркылы эшчеләр арасында көрәш настроениеләренең үсүен күрсәтүдә файдалану кебек моментлар булганы шикелле, милли халык музыкасы да крестьян-авыл тормышын бирү юлында уңышлы файдаланылган. (Г.Рәхим. “Эшче” операсы турында).*

**Чыганакның төрен билгеләгез. (3 балл)**

______________________________________________________________________

**Ул кайсы елда язылган (өзектән дәлилләр китерегез)? (3 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**Автор пролетариат идеологиясен гәүдәләндергән опера нинди билгеләрне үз эченә алырга тиеш дип саный? Ул билгеләрне тексттан алып күчереп языгыз (6 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!**